Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы

Урта Тигәнәле гомуми урта белем бирү мәктәбе

муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

Фәнни – зләнү тикшеренү эше:

# “Урта Тигәнәле авылында балалар хәрәкәте тарихы”


Эшне башкардылар:

10 сыйныф укучылары

Заббарова Ильгинә,

Ситдиков Динар

педагог-оештыручы
Зайнуллина Алия Сөләймановна


2017 уку елы

Эчтәлек

I. Кереш.
II. Төп өлеш
1. Ветеран - пионерлар
2. Мәктәп архивы
III. Йомгаклау
Кулланылган әдәбият исемлеге
Кушымта

## I. Кереш .

Совет властенең беренче еллары... Эшчеләр һәм крестьяннар ленинчы большевиклар җитәкчелегендә яңа тормыш төзиләр, дошманнарга каршы көрәшәләр. Балалар да өлкәннәргә булышырга телиләр. Алар илнең төрле почмакларында төрле отрядларга, группаларга берләшеп, үзләрен спартакчылар, яшь коммунарлар, яшь коммунистлар дип атыйлар. Партия комсомолга балаларның бердәм коммунистик оешмасын төзү бурычын йөкли.

1922 елның 12 февралендә Мәскәүдә Кызыл Преснядагы типографиянең бер цехына ярты йөзгә якын бала җыела. Алар уйныйлар, җырлыйлар, барабан тавышлары астында Мәскәү урамнары буйлап горур атлап үтәләр. Бу - иң беренче пионер отрядларының берсе була.

1922 елның 19 маенда комсомолның 2 нче Бөтенроссия конференциясе карар бирә: Мәскәүлеләр үрнәгендә һәркайда пионер отрядлары оештырырга. Бу көн пионер оешмасы туган көн булып санала. Шушы көннән башлап илебезнең барлык җирендә, мәктәпләрдә балалар оешмалары төзелә.

## II. Төп өлеш

Без бүген сезне туган мәктәбебездәге пионер оешмасының тарихы белән таныштырып китәрбез.

Эзләнү- тикшерү эшебезнең максаты:

“Урта Тигәнәле авылы балалар оешмасының барлыка килүен, эшчәнлеген өйрәнү һәм мәктәптәге музейга бу мәгълүматларны туплау”.

Бурычларыбыз:

-ветеран пионерлар белән очрашып әңгәмәләр алып бару;
-мәктәп архивында пионер оешмасына кагылышлы документлар белән танышу.

Бу эзләнү эшен без ике юнәлештә алып бардык. Урта Тигәнәле мәктәбе 1951 елда урта мәктәп статусын алган, аңарчы ул 7 еллык мәктәп булган. Тирә-юнь татар авыллары өчен дистәләгән еллар дәвамында ул “альма - матер” була. Шул мәктәптә күрше Түбән Тигәнәле, Зур Тигәнәле, Коры Көрнәле, Кыр Шонталасы, Урманасты Шонталасы авыллары, хәтта бер чор Яуширмә (Чистай районы) балалары да белем ала.1980-1993 елларда, рус-татар мәктәбе статусын алгач, Болак Тигәнәлесе, Родники авылларыннан килеп, биредә чуваш һәм мордва балалары укый. Ә 1993 елда мәктәптә урта һәм түбәнтигәнәлеләр генә кала.

Беренче пионер отрядлары 28 – 30 елларда барлыкка килгән. Эзләнүебезнең беренче юнәлеше – пионер-ветераннар белән очрашу, әңгәмә алып бару, искә төшерүдән гыйбарәт булды. Авылыбызның иң өлкән кешесе - Заббарова Җүвәйрә

апага ( минем зур әбием) юл тоттык. Аңа инде 96 яшь (1920 елгы). Минем әбием – 30 нчы еллар пионеры була. Икенче ветеранызыбыз – Амирова Гаян апа – (1929 елгы) – 40нчы еллар пионеры.Өченче ветеранызыбыз Махмутов Галимҗан абый ( 1941елгы) – 50нче еллар пионеры. Калимуллин Наил абы  - ( 1949 елгы) – 60нчы еллар пионеры. Садыкова Лилия, Заббарова Алия апалар – 80нче еллар пионерлары.

Әңгәмәләребез бик кызык үтте. Һәркайсының хатирәләре бик җылы иде. Ул елларын бик сагынып сөйләделәр.

Пионер булу ул – һәрвакытта һәм һәрнәрсәдә үзеңдә Ленинга хас хезмәт сөючәнлек,намуслылык,инсафлылык,укуда тырышлык,белемнәреңне тормышта куллана белергә, Ватанга мәһаббәт тәрбияләргә дигән сүз-ул-дип тәрбияләделәр безне дип сөйләделәр алар. Дружина сборлары, быргы, барабан тавышлары,күңелле тормышыбыз әле һаман исебездә диләр.

Без бик эшләп үстек, картларга һәрдаим булыша идек. Ничектер арабызда ялкаулар булганнарын хәтерләмибездә диләр. Әби-бабайларга сулар ташый идек, утыннарын кисеп- ярып, өеп куя идек, кышкы көннәрдә карларын көрәдек, яз көне бакча эшләрендә булышып, өйләрен, идәннәрен юып чыгара идек. Әле колхозга булышырга да өлгерә идек,атна саен ял көне көл,кошлар тизәге җыя идек,фермада бозаулар карап,дуңгызларга күмер җыеп,куяннар ашатып йөри идек. Бик күңелле, ярыш формасында макулатура һәм металлалом җыю көннәре дә исләрендә калган ветераннарның.

Мәктәптә икеле алучыларга, ялганларга яратучыларга, мактанчыкларга, каракларга карата кискен көрәш бара иде. Җыелышларда үзебез тәнкыйтьләп тәрбияли идек диләр. Мәктәпкә мәҗбүри рәвештә галстук, значок, формадан йөрергә иде. Ак якалар чиста, галстуклар үтүкләнгән булырга тиеш иде. Пионер оешмасы безне тәртипкә өйрәтте диләр ветераннарыбыз. Тырыш, намуслы, туган җиребезне ярата торган кешеләр булып үстек без диләр алар.

Алар үзләренең <u>вожатыйларын</u> да хәтерлиләр. Менә алар:

- Парамонова Анна
- Гайнуллина Гайшә
- Степанова Татьяна
- Мазидуллина Шәмсенур
- Зайнуллин Рәүф
- Хасаншина Зөләйха
- Идиятуллина Зөлфия
- Гаффарова Рәшидә

Озак еллар чын-чын вожатый булып эшләүче Исхакова Зөләйха (Хасаншина) апаны һаман онытмыйлар әле. Зөләйха ападан соң озак еллар Курмаева Рәшидә (Гаффарова) апа үз эшен бик яратып башкарды. Алар чын укытучы кебек булганнар, күп белгәннәр, балаларны да күп нәрсәгә өйрәтә алганнар. Алар шат табигатьле, тынгысыз да, төрле- төрле уеннар, күңел ачулар оештырганнар.

Эзләнә торгач тагын бик кызыклы мәгълүматка тап булдык без. Иң актив пионерларны - иң яхшы лагерьга юллама белән бүләкләгәннәр. Менә минем туган апам: **Заббарова Зөлфия Вәли кызы**. Ул 1948 нче елның июлендә Алексеевск районы Урта тигәнәле авылында туып үсә. 5 нче сыйныфтан алып 8 нче сыйныфка кадәр 5 ле билгеләренә генә укып, һәр эштә дә актив катнашканы өчен аны **“Артек”** лагеренә путевка белән бүләклиләр.Ул 1961нче елның ноябрендә Артекның “Горный” лагерена китә.Татарстаннан Артекка бары тик 4 кеше генә бара. Артекта

лагерендә ял итү бик кызык булган, аларны слётларга, Севостополь, Малахов-Курган кебек тарихи урыннарга алып барганнар. Бу хатирәләрне туган апам миңа бик сөенеп сөйләде.

Җәйге елларда мәктәпнең “Алга” колхозы тарафыннан оештырылган үз пионер лагере да булган. Авылдан шактый еракта – урманда. Андагы ялның кызыклыгын сөйләп бетерә алмыйлар. Казанда пешергән ашларның, боткаларның, көлдә пешкән бәрәңгеләрнең тәме һаман да тел очында тора диеп хәзер дә сагынып сөйлиләр алар.

Эзләнүебезнең икенче юнәлеше – мәктәптәге архивны барлау.

Быргы, барабан (бездә әле алар сакланалар. Очрашу кичәләрендә, пионер туган көненә багышланган кичәләрдә алар алар безнең кунакларыбыз) Барабанчы, быргычы булу – иң дәрәҗәле эш дип саналган. Ул “алдан атлау, алга өндәү” дигән сүз. Дружинаның байрагы һәм һәр отрядның үз флагы булган. Пионерлар шушы байрак янында тантаналы вәгъдә биргәннәр. Пионерларның үзләренең газета-журналлары булган. Берничәсе бездә дә саклана. Үзләре дә һәрдаим газеталар чыгара торган булганар, альбомнар төзегәннәр. Анда пионерлар мәктәп тормышын,уку алдынгыларын,эш нәтиҗәләрен яктырта торган булганнар.

## III. Йомгаклау

Пионер оешмасында балалар бердәм, дус, актив, берсен – берсе кайгыртучан, гадел, намуслы булырга өйрәнгәннәр. Барлык эшләре туган илне яратырга, өлкән буынның эшләре белән горурланырга һәм аларның эшләрен дәвам итәргә юнәлдерелгән. Һәр баланы мөстәкыйльлеккә, хезмәт яратырга өйрәткәннәр. Бер бала да үз проблемасы белән читтә калмаган, яннарында һәрвакыт булышучы дуслары, өлкән кешеләре булган. Бу елларны барлык ветераннар җылылык белән искә алалар.

## Көтелгән нәтиҗә.

Балалар хәрәкәте тарихы ул – тулы тормыш. Ә тормыш ул – алга бару, төгәл эшләр. Балалар хәрәкәтен өйрәнеп без күп нәрсәләр белдек, элеккеге пионерлар актив, тату-дус, уңган, булган,тәртипле, олыларны олы, кечеләрне кече итүче, һәрвакыт ярдәмгә килүче булганнар. Мәктәп ул – безнең икенче йортыбыз. Андагы тәртип өйдәге кебек булырга тиеш. Балалар хәрәкәте тарихын өйрәнү һәм белү, безгә укуда да, эштә дә зур этәргеч бирде. Без тагын да ныгырак коллектив булып тупландык. Мәктәптә укулары тагын да күңеллерәк, кызыгырак була башлады. Укучыларның активлыгы, бер –берсенә ярдәмгә килүе үсә төште, йөрәкләрендә сүнми торган шәфкатьлелек, игелеклелек ялкыны кабынды.

## Кулланылган әдәбият исемлеге.

1.А.Зебзеева. Пионер тормышы әлифбасы. Казан татарстан китап нәшрияты, 1981
2. Урта Тигәнәле урта мәктәбендәге альбомнар, музей материаллары.
3.Б.Шәйхетдинов. Тигәнәле–туган җирем.Казан “Матбугат йорты”нәшрияты, 2005
Кушымта. Видеоязмалар.